КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 2 ноябрь г.Казань № 1000

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 июль, 636 нчы карары белән расланган 2019 – 2024 елларга Татарстан Республика-сында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 июль, 636 нчы карары белән расланган 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту буенча төбәк программасына (алга таба – Төбәк программасы) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Төбәк программасы паспортының «Елларга һәм чыганакларга бүлеп, Төбәк программасын финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Елларга һәм чыганакларга бүлеп, Төбәк программасын финанслау күләме

2019 – 2024 елларда Төбәк программасын финанслауның гомуми күләме 1 756 274,2 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Барлыгы | Шул исәптән | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республи-касы бюджеты акчасы | җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | бюджеттан тыш акча |
| 2019 | 110 306,6 | 6 409,9 | 27 313,7 | 76 583,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2020 | 105 700,2 | 14 995,6 | 63 928,6 | 26 776,0 |
| 2021 | 167 570,3 | 31 838,4 | 135 731,9 | 0,0 |
| 2022 | 297 894,1 | 48 236,5 | 205 639,6 | 44 018,0 |
| 2023 | 295 360,0 | 56 100,0 | 239 260,0 | 0,0 |
| 2024 | 779 443,0 | 36 100,0 | 153 760,0 | 589 583,0 |
| Бар-лыгы | 1 756 274,2 | 193 680,4 | 825 633,8 | 736 960,0 |

Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;

1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Кирәкле чаралар бик кыйммәтле булу аркасында, мәсьәләне суүткәргеч хуҗалыгы предприятиеләренең үз акчасы хисабына хәл итеп булмый. Бу мәсьәләне хәл итү максатларында, расланган финанслау күләменнән чыгып, Төбәк программасына халык күп санда булган торак пунктларда 10 чара кертелгән.»;

2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы халкы өлеше» һәм «Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән Татарстан Республикасы шәһәр халкы өлеше» күрсәткечләре мәгънәләре Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән килештерелде.»;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «3. Төбәк программасының ресурслар белән тәэмин ителеше

2019 – 2024 елларда Төбәк программасын финанслауның гомуми күләме 1 756 274,2 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Акча барлыгы | Шул исәптән | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | бюджеттан тыш акча |
| 2019 | 110 306,6 | 6 409,9 | 27 313,7 | 76 583,0 |
| 2020 | 105 700,2 | 14 995,6 | 63 928,6 | 26 776,0 |
| 2021 | 167 570,3 | 31 838,4 | 135 731,9 | 0,0 |
| 2022 | 297 894,1 | 48 236,5 | 205 639,6 | 44 018,0 |
| 2023 | 295 360,0 | 56 100,0 | 239 260,0 | 0,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2024 | 779 443,0 | 36 100,0 | 153 760,0 | 589 583,0 |
| Бар-лыгы | 1 756 274,2 | 193 680,4 | 825 633,8 | 736 960,0 |

Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

5 бүлекнең 2 таблицасындагы 4 позициянең 2 графасында «Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрендә су белән тәэмин итү өчен су алу узелы төзү» сүзләрен «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәре өчен су алу узелы булган су белән тәэмин итү системасы төзү» сүзләренә алыштырырга;

6 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Өстенлекле технологияләрне файдалануга күчү

Суүткәргеч системаларының нәтиҗәлерәк эшләве өчен Төбәк программасы белән күздә тотылган Татарстан Республикасында су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту чаралары, оборона-сәнәгать комплексы оешмалары тарафыннан һәм халык сәламәтлегенә куркыныч янауны бәяләүне исәпкә алып эшләнгән технологияләрне файдаланып, су әзерләүнең һәм су чистартуның өстенлекле технологияләре белешмә сүзлегенә кертелгән технологияләрне кулланып гамәлгә ашырылырга тиеш.»;

Төбәк программасына теркәлгән 1 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

Төбәк программасына теркәлгән 2 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

Төбәк программасына теркәлгән 3 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

Төбәк программасына теркәлгән 4 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

Төбәк программасына теркәлгән 5 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

«2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 2 ноябрь, 1001 нче карары редакциясендә)

«2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү

(млн.сум)

| Бурычның исеме | Финанслау чыганагы | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | Акча барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 1 нче бурыч. Татарстан Республикасында телләр сәясәтенең норматив хокукый тәэмин ителешен камилләштерү | Татарстан Республикасы бюджеты | 1,75 | 0,6 | 1,2 | 0,46 | 0,46 | 0,26 | 0,46 | 0,46 | 0,46 | 6,11 |
| 2 нче бурыч. Татарстан Республикасы дәүләт телләре буларак рус һәм татар телләренең тигез кулланылуына булышлык күрсәтү | Татарстан Республикасы бюджеты | 16,2 | 21,268 | 30,25 | 29,75 | 27,2 | 22,35 | 23,9 | 23,0 | 23,9 | 217,818 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 нче бурыч. Татарстан Республикасында татар һәм рус телләрен өйрәнүнең һәм татар һәм рус телләрендә белем бирүнең бербөтен системасын үстерү; Татарстан Республикасыннан читтә татар телен өйрәнүгә һәм татар телен өйрәтүгә булышлык күрсәтү | Татарстан Республикасы бюджеты | 84,16 | 82,763 | 83,57 | 62,07 | 57,96 | 58,12 | 53,89 | 57,54 | 59,62 | 599,693 |
| 4 нче бурыч. Татарстан Республикасында татар һәм рус телләрен саклау һәм үстерү процессларын фәнни һәм фәнни-методик тәэмин итү | Татарстан Республикасы бюджеты | 28,22 | 39,7 | 25,87 | 39,17 | 26,91 | 19,96 | 19,81 | 14,8 | 15,04 | 229,48 |
| 5 нче бурыч. Татарстан Республикасында яшәүче халыклар телләрен саклау һәм үстерү | Татарстан Республикасы бюджеты | 15,58 | 16,269 | 16,06 | 11,45 | 12,17 | 9,2 | 10,7 | 10,04 | 10,14 | 111,609 |
| 6 нчы бурыч. Татарстан Республикасында дәүләт телләренең һәм башка телләрнең социаль статусын күтәрү һәм | Татарстан Республикасы бюджеты | 19,09 | 21,2 | 23,5 | 18,6 | 16,55 | 13,05 | 14,15 | 14,15 | 14,25 | 154,54 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| аларны популярлаш-тыру | | | | | | | | | | | |
| 7 нче бурыч. Проект-грамманың нәтиҗә-ләрен мониторинг-лау, Татарстан Рес-публикасында этно-телләр вәзгыятен анализлау | Татарстан Респуб-ликасы бюджеты | 2,4 | 2,4 | 1,65 | 3,0 | - | - | 0,5 | 3,42 | - | 13,37 |
| Программа буенча барлыгы | Татарстан Респуб-ликасы бюджеты | 167,4 | 184,2 | 182,1 | 164,5 | 141,25 | 122,94 | 123,41 | 123,41 | 123,41 | 1 332,62 |